

Быел бу фестиваль-конкурс Мордовия-дә 25нче тапкыр vтәчәк. Үткән атнада фестиваль-конкурс регионыбыз районнары буйлап сәяхәт итә башлады. Һәрбер район мәдәни ижат жимешләре белән vзенә билгеләнгән кондә таныштыра.  Аннары “ин-иннәребез” республикабыз сәх-нәсендә ярышыр. Гала-концертта безнен хозурга регионыбыз мактанырлык номерлар белән очрашачакбыз.      Шулай,  Темников районы Мәдәният йорты сәхнәсендә “Шумбрат, Мордовия” фестиваль-конкурсынын беренче конендә (2021 елнын 12 ноябрендә) Аксел, Тархан авылларыннан “Йолдызлар” һәм “Сандугачлар” ансамбльләре милли жырларыбызны ишеттерделәр, татар туе еласын кvрсәттеләр.
Ә 14 ноябрьдә Кадошкино районында “Шумбрат, Мордовия!”нен район туры vтте. Чарада рус, мукшы милли номерлары белән беррәттән татарларыбыз жырлары, биюләре район сәхнәсендә матур ян-гырады. Биредә Большие Поляныдан “Дуслык” ансамбле, Латышовкадан Донская Рушания Фәрит кызы ижат жимешләре белән сәхнәне ямьләндерделәр.
Менә шулай регионыбыз буйлап “Шумбрат, Мордовия!” фестиваль-конкурсыбыз атлый башлады. Темников белән Кадошкино районнарында татарча матур номерлар белән чыгыш ясадылар; бvтән районнар чыгышын котәбез.